ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 057 от «19» 03 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы Башлыгының 2022 елның 9 февралендәге
011 нче карары белән расланган
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы җирле үзидарә органнарында муниципаль
вазыйфаларны биләүче затларга һәм муниципаль
хезмәткәрләргә премия бирү турындагы
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Мамадыш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 3-25 номерлы карары нигезендә к а р а р б и р ә м:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 9 февралендәге 011 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә премия бирү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-Нигезләмәнең 3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Квартал саен бирелә торган премия күләме айлык акчалата түләүдән процент нисбәтендә билгеләнә.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплы итеп Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе В.Н.Фәизовны билгеләргә.

Муниципаль район Башлыгы
вазифаларын башкаручы Р.Р.Сәмигуллин

000 060